| СОВЕТ БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 14.05.2025 | № 131 |

Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге Советының «Борнак авыл җирлеге башлыгы,Борнак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 102 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында
(2023 елның 14 март 71 нче номерлы, 2024 елның 18 июле 105 нчы номерлы, 2024 елның 31 октябре,111 нчы номерлы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 нче апреле 228 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 30 нчы апреле 315 нче номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 нче декабрендәге 99 нчы номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «13990» санын «15389» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «19173» санын «21091» санына алмаштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге башлыгы, Борнак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 2 пунктында «12,86» санын «15,48» санына алмаштырырга.

Тәртибенең 2 пунктында «12,86» санын «15,48» санына алмаштырырга.

1.4. Борнак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибенең 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Хабибуллин